# КАРАР

**2022 елның 24 ноябре** **№ 2**

**Кукмара муниципаль районы Ошторма-Юмья авыл җирлегенең Иске Юмья авылында «Кукмара муниципаль районы Ошторма-Юмья авыл җирлегенең Иске-Юмья авылында үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 2021 елның 26 ноябрендәге 1 номерлы Иске Юмья авылы гражданнар җыены карарына үзгәрешләр кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыены нәтиҗәсе турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә 2022 елның 24 ноябрендә түбәндәге мәсьәлә буенча узган гражданнар җыены нәтиҗәләре белән гражданнар җыены беркетмәсе төзелде:

«Кукмара муниципаль районы Ошторма-Юмья авыл җирлегенең Иске Юмья торак пунктында үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 2021 елның 26 ноябрендәге 1 номерлы Иске Юмья авылы гражданнар җыены карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертү белән килешәсезме:

- 2 пунктка түбәндәге эчтәлекле яңа абзацны өстәргә:

«- Иске Юмья авылында суүткәргеч челтәрләрне һәм су белән тәэмин итү системаларын ремонтлау, төзекләндерү, грунтны кул һәм экскаватор белән эшкәртү, торба үткәргеч урнаштыру, ремонтлау, бетон боҗралар, капкачлар һәм люклар сатып алу һәм урнаштыру, (материаллар сатып алу, экскаватор һәм манипулятор хезмәтләре өчен түләү, килешү буенча эшләр өчен түләү, проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру);»

«РИЗА» «КАРШЫ».

Гражданнар җыенының йомгаклау беркетмәсе нигезендә:

Сайлау хокукына ия җыенда катнашучылар исемлегенә 470 кеше кертелде, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар җыенында катнашучылар саны – 251.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«Әйе» позициясе өчен җыенда катнашкан 251 кеше тавыш бирде;

«Юк» позициясе өчен гражданнар җыенында катнашкан 0 кеше тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә, гражданнар җыены карар бирде:

1. Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Ошторма-Юмья авыл җирлеге Иске Юмья авылында гражданнар җыенын узган дип, гражданнар җыенының нәтиҗәләрен дөрес дип танырга.

2. Түбәндәге мәсьәләне: «Кукмара муниципаль районы Ошторма-Юмья авыл җирлегенең Иске Юмья торак пунктында үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 2021 елның 26 ноябрендәге 1 номерлы Иске Юмья авылы гражданнар җыены карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертү белән килешәсезме:

- 2 пунктка түбәндәге эчтәлекле яңа абзацны өстәргә:

«- Иске Юмья авылында суүткәргеч челтәрләрне һәм су белән тәэмин итү системаларын ремонтлау, төзекләндерү, грунтны кул һәм экскаватор белән эшкәртү, торба үткәргеч урнаштыру, ремонтлау, бетон боҗралар, капкачлар һәм люклар сатып алу һәм урнаштыру, (материаллар сатып алу, экскаватор һәм манипулятор хезмәтләре өчен түләү, килешү буенча эшләр өчен түләү, проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру);»

«РИЗА» «КАРШЫ».

- кабул ителгән дип таныргa.

3. Гражданнар җыенның нәтиҗәләрен мәгълүмат стендларында, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталында Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында www.pravo.tatarstan.ru адресы буенча урнаштырырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Ошторма-Юмья авыл җирлеге башлыгы: С.В. Тимофеев